СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
***РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН***
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

***ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ***
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге советы**
карары

**“29” ноябрь 2023 ел** **№ 103**

Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августында кабул ителгән “Җир салымы турында” 64номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 77 номерлы карары редакциясендә)

2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Уставына таянып, Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 64 номерлы “Җир салымы турында”гы карарына (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 77 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2.4 нче пункт астындагы “һәм объектлар белән” сүзләрен “һәм (яки) объектлар белән”, “объектка туры килә торган җир участогына хокуклы өлеш” сүзләрен “күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлешләре” һәм “һәм объектларга” сүзләрен “һәм (яки) объектларга” сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми рәвештә бастырылганнан соң бер ай узгач кына үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ